**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2019 Балык Бистәсе штп. № 113пи

2019 елда балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карары белән расланган (ТР МК ның 2018 елның 19 ноябрендәге 1006 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) “2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт үсеше” дәүләт программасының “2014 – 2021 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру” ярдәмче программасын һәм балалыкны яклау, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен зарури шартлар булдыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 4 сентябрендәге “Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренә норматив чыгымнарны раслау турында” 748 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 31 мартындагы “Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында” 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 1272 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга (кушымта итеп биреләләр):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составын;

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2019 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру” муниципаль (үзидарәлек) программасын;

Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында оператив мәгълүмат бирүнең хисап формасын.

2.”Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлеге” үзидарәлек казна учреждениесенә, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” үзидарәлек казна учреждениесенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә тәэмин итәргә:

беренче чиратта ата-ана кайгыртучылыгыннан мәхрүм калган, инвалид, сәламәтлек мөмкинлеге чикләнгән, ягъни физик һәм (яки) психик үсешләрендә кимчелекләре булган балаларның, короллы һәм халыкара низаглар, экологик һәм техноген һәлакәтләр, табигать бәла-казалары корбаны булган балаларның, качаклар һәм күчеп килергә мәҗбүр булган гаиләләрнең балаларының, гадәттән тыш авыр, көтелмәгән шартларга дучар булган, җәбер-золым, көчләү корбаны булган балаларның, ирektән мәхрүм ителеп тәрбия колонияләрендә җәза үтәүчеләрнең балаларының, девиант (иҗтимагый хәтәр) тәртиплеләр өчен булган мәгариф оешмаларында укучы, белем һәм тәрбия бирүнең аерым шартлары һәм махсус педагогик якын килү таләп ителгән балаларның, килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тереклек эшчәнлеге объектив рәвештә бозылган һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән җиңеп чыга алмаган балаларның, җан башына керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы зурлыгыннан түбән булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге “Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидия һәм стипендияләр бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” 542 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган балага айлык пособияне алучы гаиләләрдәге балаларның, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслашкан оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең, социаль хәвефле хәлдәге гаиләләрдән булган балаларның (алга таба – авыр тормыш хәлендәге балалар) ялын оештыруны;

балаларны тәрбиягә алган гаиләләрдәге ятим балаларның, мәгариф оешмалары тарафыннан көндезен була торган итеп оештырылган лагерьлар сменаларында, шулай ук Татарстан Республикасы буенча шәһәр яны лагерьларының профильле сменаларында балаларның ялын һәм сәламәтләнүен оештыруны;

практика узу чорында һөнәри югары белем бирү оешмалары студентларын балаларны сәламәтләндерү оешмалары эшенә җәлеп итүне;

балалар һәм яшьләр ялы өчен оештырылучы республика профиль сменаларына иҗади сәләтле балаларны сайлап алуны, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активистларын, волонтерларны, республика, бөтенрәсәй, халыкара конкурслар, ярыш һәм олимпиада җиңүчеләрен һәм призерларын укуда, балалар иҗатында, спорттагы казанышлары һәм балалар һәм яшьләр хәрәкәтендә актив катнашкан өчен бүләк сыйфатында Кара диңгез буена җибәрелүче балаларны туплауны;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы белем бирү мәктәпләре, “Балык Бистәсе агротехник техникумы” урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, ““Дельфин” спорт-сәламәтләндерү комплексы” үзидарәлек бюджет учреждениесе спортзаллары һәм спорт мәйданчыклары базасында физкультура-масса эшен алып баруны;

“Ямаш ТГББМ” ҮБГББУ *(“Ямаш төп гомуми белем бирү мәктәбе” үзидарәлек бюджет гомуми белем бирү учреждениесе)* (МБОУ «Ямашевская ООШ») базасында палаткалы “Өмет” («Надежда») лагеренда профильле смена оештыруны;

Татарстан Республикасының Яшьләр эше буенча министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы ял оешмаларының профильле сменаларына юллама алган балалар турында мәгълүматны социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – ЕГИССО) бирү буенча эшне;

2019 елга календарь эш планы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының спорт-масса чаралары һәм ярышларын, командалар очрашулары һәм беренчелекләрен уздыруны.

3.”Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге” үзидарәлек казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

контракт системасы турындагы законнар белән билгеләнгән тәртиптә торги нәтиҗәләре буенча тәгаенләнгән сәламәтләндерү оешмалары республика сменаларына (шул исәптән профильлеләргә дә) җибәрелүче балалар өчен юлламалар булдыруга үзидарәлек контрактлары төзүне;

торги нәтиҗәләре буенча тәгаенләнгән сәламәтләндерү оешмалары республика сменаларына (шул исәптән профильлеләргә дә) җибәрелүче балалар өчен юлламалар булдыруга төзелгән үзидарәлек контрактлары буенча үзвакытында финанслауны һәм акча средстволарын күчерүне;

балалар һәм яшьләр ялын оештыруга методик ярдәмне һәм мониторингны:

-белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезен була торган лагерьлар сменасына;

-белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезен була торган хезмәт һәм ял лагерьларына;

-белем бирү оешмалары белән бергәлектә 2019 елның 1 маеннан 31 августына чаклы “Хәвефсез җәй – 2019” операциясен үткәрүгә;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар иҗат үзәге””өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе базасында белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезен була торган лагерьлар сменасында эшләүче кадрларны укытуга;

- белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезен була торган (мәктәп яны), вакытлы (кыска сроклы) лагерьлар сменасында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруга;

- көндезен була торган хезмәт һәм ял лагерьлары (ЛТО) сменасында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга;

-лагерьларның бөтен сменаларын югары квалификацияле кадрлар белән туплауга;

-балалар ялын оештыру вакытында хезмәтне саклау кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуга;

-сәламәтләндерү оешмаларында янгынга каршы куркынычсызлыкны тәэмин итүгә;

-сәламәтләндерү оешмаларында санитария нормалары һәм кагыйдәләре таләпләрен үтәүгә;

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар иҗат үзәге””өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе белән бергәлектә юлламалар алган балалар турындагы, авыр тормыш хәлендә калган, үзидарәлек һәм дәүләт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең һәм коммерциячел һәм

коммерциячел булмаган (үзидарәлек һәм дәүләт оешмаларыннан гайре) оешмалар хезмәткәрләренең балалары, белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезен була торган лагерьларда һәм хезмәт һәм ял лагерьларында ял иткән балалар турында мәгълүматны ЕГИССО га тапшыру буенча эшне.

4. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Идарәсенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарындагы Территориаль бүлегенә (Миличихина И.Л.) тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезен була торган лагерьлар, көндезен була торган хезмәт һәм ял лагерьлары, палаткалы “Надежда” (“Өмет”) профильле смена лагерен файдалануга үзвакытында күзәтчелекне һәм аларны кабул итүне (график буенча) оештыруны;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләрне кертүне, төркемле йогышлы чирләр барлыкка килүне кисәтү максатларында автомобиль транспорты белән ташу буенча санитария-эпидемиология таләпләрен үтәүне һәм оешкан балалар коллективларының бөтен төр транспортта районнан читкә чыгуын килештерүне;

сәламәтләндерү оешмаларын аларның санитария кагыйдәләренә һәм нормаларына туры килүен тикшерү максаты белән һәр сменаны ачар алдыннан комплекслы тикшерү уздыруны.

5.”Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге” сәламәтлек саклау федераль бюджет учреждениесенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарындагы филиалының Балык Бистәсе бүлегенә (Фәйзуллин И.Г.) тәкъдим итәргә:

5.1)үткәрүне тәэмин итәргә:

5.1.1)түләтүсез:

ял оештыруның гамәлдәге санитария кагыйдәләре һәм нормаларына туры килүенә санитария-эпидемиология эксперизасын;

ял оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналның профилактик медосмотрларын һәм гигиена укуларын, ял оешмалары ачылыр алдыннан лаборатор-инстументаль тикшерүләрне, шулай ук гельминтозага (глист күкәйләренә тизәк анализы, лямблия циста һәм энтеробиозга соскоб) тикшерүләрне, эчәк инфекцияләрен китереп чыгаручыларны таратуга тикшерүләрне, корсак тифына канга серологик тикшерүне;

укудан буш вакытта һәм каникуллар чорында вакытлыча мәшгульлеккә рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарның медосмотрларын;

Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча кеше иминлеген һәм кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт һәм дәүләт заданиесе кысаларында аның территориаль бүлекләренең күрсәтмәләренә ярашлы рәвештә сәламәтләндерү оешмасы ачылу алдыннан кимерүчеләргә һәм талпаннарга каршы эшкәртүләрнең нәтиҗәлелегенә контрольне;

5.1.2) төзелгән гражданлык-хокукый килешүләр нигезендә:

балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләнүен оештыру эше барышында балаларның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өчен лаборатор-инструменталь тикшерүләрне;

5.2)бөер синдромлы геморрагик бизгәкне кисәтү максатларында сәламәтләндерү оешмалары ачылу алдыннан белем бирү оешмалары белән кимерүчеләргә каршы чаралар үткәрүгә килешү төзүне;

5.3)талпан энцефалиты, боррелиозны кисәтү максатларында, эшкәртүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тотып, урман бетенә каршы эшкәртү үткәрүгә килешү төзүне;

6. Россия ЭЭМ ның Балык Бистәсе районы буенча бүлегенә (Мостафин Н.Ф.) тәэмин итүне тәкъдим :итәргә:

"Надежда" ("Өмет") палаткалы лагеренда профильле сменада территорияне, җәмәгать тәртибе һәм иминлекне тәүлек әйләнәсе саклауны һәм Россия ЭЭМ ның Балык Бистәсе районы буенча бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан кизү торуны оештыруны;

закон нигезендә балаларны лагерьга оешкан төстә китерүче һәм кире кайтаручы транспорт чараларын озата баруны;

районнан читтәге шәһәр яны лагерьларының профильле сменаларына баручы балалар төркемнәренең бару юлында һәм булу урыннарында җәмәгать тәртибен саклау һәм озата баруны;

балалар һәм яшьләрнең ялы чорында хокук тәртибен тәэмин итүне.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Ногманова И.М.) 2019 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча чыгымнарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында каралган средстволар исәбенә, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр исәбенә финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

8."Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (Китаев М.Р.) тәкъдим итәргә:

"Надежда" ("Өмет") палаткалы лагереның профильле сменасына күрсәтелгән учреждение заявкасына ярашлы рәвештә контракт (килешү) нигезендә медицина кадрларын туплауны;

укудан буш вакытта һәм каникуллар чорында вакытлыча эшкә урнаштыруга рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарның, шулай ук ял итү оешмаларында балалары белән ял итүче ата-аналарның медосмотрларын оештыруны түләү алмыйча тәэмин итүне;

ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналның сезонлы осмотрларын түләү алмыйча балалар һәм яшьләр ялын оештыруга бүленә торган средстволар исәбенә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 12 апрелендәге " Зарарлы һәм (яки) хәтәр производство факторлары һәм аларны башкарганда алдан һәм периодик рәвештә мәҗбүри медицина осмотрлары (тикшерүләре) үткәрелә торган эшләр исемлеген һәм авыр эшләрдә һәм зыянлы һәм (яки) хәтәр хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә алдан һәм периодик рәвештә мәҗбүри медицина осмотрлары (тикшерүләре) үткәрү Тәртибен раслау турында" 302-н номерлы Боерыгы таләпләренә яраштлы рәвештә тәэмин итәргә;

ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналга сезонлы осмотр үткәрү кысаларында түләүсез флюорография тикшерүен тәэмин итәргә;

белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезен була торган лагерь сменаларында, көндезен була торган хезмәт һәм ял лагерьларында балалар һәм яшьләрне территориаль принцип буенча дәвалау-профилактика учреждениеләре медицина хезмәткәрләре көче белән медицина тәэмин итүен гамәлгә ашырырга;

медицина хезмәткәрләренең санитария-агарту эше планына сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү, балигъ булмаганнар арасында алкоголизм, наркомания һәм токсикоманияне кисәтү буенча мәгълүмати-агарту чараларын кертергә;

хроник чирләре булган, шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган яшьләре дүрттән алып 17 гә тикле булган балаларга "Детская" (озатусыз) яки "Мать и дитя" (ата-аналарның берсе/законлы вәкил озатуында) юлламалары буенча шифаханәдә савыктыру оештырырга;

санаторий-курорт оешмаларына юлламалар алган авыр тормыш хәлендә калган балалар турында ЕГИССО га мәгълүмат бирү буенча эшне тәэмин итәргә.

9.Россия ГХМ БИ нең ТР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм кисәтү эше Идарәсенең Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлекчәсенә (Ещев О.Л.) һәм "Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 7 отряды" ФГКУ нең 128 номерлы янгын-коткару частена (Ещев О.Л.) тәкъдим итәргә:

һәрбер сменаны ачар алдыннан янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә туры килүен тикшерү максатында сәламәтләндерү оешмаларын комплекслы тикшерү оештырырга;

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру чорында сәламәтләндерү оешмаларында һәм гаммәви ял урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүгә күзәтчелекне тәэмин итәргә;

10."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы киноучреждениесе" үзидарәлек бюджет учреждениесенә каникуллар чорында балалар һәм яшьләр өчен киносеанслар оештыруны, мультфильмнар күрсәтүне тәэмин итәргә;

11."ТАТМЕДИА" АҖ филиалы "Авыл офыклары" Балык Бистәсе газетасына (Минһаҗева Т.Г.) 2019 елгы сәламәтләндерү кампаниясенә әзерлек һәм аны үткәрү барышын гаммәви мәгълүмат чараларында яктыртуны тәкъдим итәргә.

12."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль заказ хезмәте" үзидарәлек казна учреждениесенә (Вәлиуллин З.Р.) тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы территориясендәге сәламәтләндерү оешмаларына юллама булдыруга үзидарәлек хаҗәтләре өчен сатып алуларны гамәлгә ашыруны;

балалар һәм яшьләр ялы белән бәйле контрактлар реестрына кертү өчен юнәлдерелгән үзидарәлек контрактларын һәм шартнамәләрен аларны алган көннән соң эш көннәре белән исәпләнүче өч көнлек срокта карауны.

13. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге" үзидарәлек казна учреждениесенә (Рәшитова Р.Г.) оештырырга:

сәламәтләндерү лагерьларында күчмә китапханәләр эшен;

сәламәтләндерү лагерьларында әһәмиятле һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар үткәрү буенча эшне.

14. “Сетевая компания” Приволжские сети ААҖ филиалы Балык Бистәсе РЭЧ нә (Хәмидуллин Р.Г.) белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган җәйге лагерьларга, шул исәптән “Надежда” палаткалы лагерена электр энергиясен өзлексез бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

15. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2019 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы барлык төр милек формасындагы оешма, учреждениеләренә тәкъдим итәргә:

медицина персоналын эшкә кабул итүнең шартнамә рәвешен күз алдында тотарга;

Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын, төзелгән килешүләр, үзидарәлек контрактлары нигезендә җирле бюджет средстволарын файдалану турында финанс хисапларын үзвакытында тапшыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар иҗат үзәге””өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесенә тапшырырга:

2019 елның 1 апреленә чаклы – барлык төрдәге лагерьларның ачылу графикларын;

2019 елның 1 июненнән алып ноябрьне кертеп сәламәтләндерү лагерена урнашканнан соң эш көннәре белән исәплләгәндә өч көнлек срокта әлеге карарга бирелгән кушымтага ярашлы рәвештә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру хакында оператив мәгълүматны;

2019 елның 1 августына кадәр – үткәрелгән чаралар турында фото- һәм видеоматериалларны үз эченә алган иҗади хисапларны.

16.2019 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссиягә:

16.1)күзәтчелек органнары катнашында сәламәтләндерү сезонына балалар лагерьларын кабул итүне оештырырга;

16.2) контрольне тәэмин итәргә:

2019 елның 1 июненнән 30 августына тикле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Ф.Әхмәдиев исемендәге балалар сәнгать мәктәбе” өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар иҗат үзәге”өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар сәламәтләндерү-белем бирү (профильле) үзәге” өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе, “Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе, белем бирү оешмалары базасындагы балалар мәйданчыклары эшенә;

кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен үтәү өчен ведомство иминлек хезмәтләре белән бергәлектә гаммәви ял урыннарында медик-санитарлык хезмәте күрсәтүгә һәм җәмәгать тәртибен саклауга;

һәрбер смена ачылыр алдыннан санитария кагыйдәләренә, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, суда кешеләр тормышын саклау, хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын һәм хезмәтен саклау, ял итүчеләрнең иминлеген саклау кагыйдәләренең үтәлүенә сәламәтләндерү оешмаларының туры килүен тикшерү максатыннан аларга комплекслы тикшерү оештыруга;

сәламәтләндерү оешмаларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар комплексын эшләү һәм гамәлгә ашыруына (шуның белән бергә бу

очракта аеруча нык игътибарны электр җиһазлары торышына, янгын автоматикасы җайланмаларының, янгын турында кешеләргә хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, беренчел янгын сүндерү средстволарының булуына һәм төзеклегенә, шулай ук хезмәт күрсәтүче персоналның янгын очрагында үз гамәлләрен белүенә юнәлтергә кирәк);

сәламәтләндерү оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре белән хезмәтне саклау буенча укулар уздыруга, хезмәтне саклау буенча инструктажлар үткәрүгә.

17. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 гыйнварындагы “2018 елда балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында”12пи номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

18.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

19. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Вафина А.К.га йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 22 мартындагы
113 пи номерлы карары белән
расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турында
Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән аларның балалар һәм яшьләр ялын оештыру өлкәсендә үзара бәйләнешен, хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында төзелгән орган булып тора.

2.Комиссия үзенең эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, үзидарәлек норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3.Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары, оешмалар белән балалар һәм яшьләр ялын әзерләү һәм оештыру буенча хезмәттәшлеген оештыру;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары,оешмалары, предприятие, учреждениеләренең балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча эшчәнлеген анализлау, Комиссия утырышларында аларның эшчәнлеге хакында хәбәрләрен тыңлау, үзенең вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

балалар һәм яшьләр ялын финанслау һәм оештыру мәсьәләләрен карау;

“2019 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру” үзидарәлек программасын тормышка ашыруга контроль.

4.Комиссия хокуклы:

балалар һәм яшьләр ялын оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты каравына кертергә;

балалар һәм яшьләр ялын оештыруда катнашучы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, оешма,

предприятие, учреждениеләрдән үз компетенциясенә караган документларны, материал, мәгълүматларны соратып алырга;

балалар һәм яшьләр ялын оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үтәлешенә мониторингны гамәлгә ашырырга.

5.Комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына балалар һәм яшьләр ялын оештыруга бүленгән средстволарны файдалану турында хисап тапшыра.

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

7.Комиссияне бер урынбасары булган рәис җитәкли.

Комиссия рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышларын алып бара, Комиссиянең эш планын раслый. Комиссия рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен рәис урынбасары гамәлгә ашыра.

8.Комиссия составына шулай ук Комиссия сәркатибе керә.

Комиссия сәркатибе Комиссия утырышларын хәзерләү буенча эшне оештыруны һәм утырышларда кабул ителгән карарларның үтәлешенә мониторингны гамәлгә ашыра. Комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча сәркатип Комиссия рәисенең һәм аның урынбасарының йөкләмәләрен үти.

9. Комиссия составына шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы оешмалары, предприятие, учреждениеләре вәкилләре, керә.

10. Комиссиянең балалар һәм яшьләр ялын оештыру мәсьәләләре буенча кабул иткән карарлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының барлык җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм . Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы оешмаларына, предприятие, учреждениеләренә үтәргә тәкъдим ителә.

11.Комиссия үз эшчәнлеген утырышларында кабул ителгән һәм Комиссия рәисе раслаган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

12.Комиссия утырышлары зарурлыктан чыгып үткәрелә, әмма кварталга бердән дә ким түгел. Утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен Комиссия рәисе тәгаенли.

13. Комиссия утырышы әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашканда вәкаләтле санала.

14. Комиссия карарлары утырышта катнашучы затларның ачык тавыш бирүе барышында гади күпчелек тавышы белән кабул ителә,утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия рәисе тарафыннан имзалана. Тавышлар саны тигез булганда, утырышта рәислек итүче Комиссия рәисенең яки аның урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 22 мартындагы
113 пи номерлы карары белән
расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча
ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Вафина А.К. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Комиссия рәисе |
| Садиков И.М. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” үзидарәлек казна учреждениесе башлыгы, Комиссия рәисе урынбасары |
| Сәмиева Ф.Г. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар иҗат үзәге”өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе методисты, Комиссия сәркатибе (килештерү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Шакиров И.З. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт, туризм буенча бүлеге” үзидарәлек казна учреждениесе башлыгы |
| Ногманова И.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Мостафин Н.Ф. | Россия ЭЭМ ның Балык Бистәсе районы буенча бүлек башлыгы, полиция полковнигы (килештерү буенча) |
| Китаев М. Р. | “Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы (килештерү буенча) |
| Миличихина И.Л. | Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Идарәсенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарындагы Территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килештерү буенча) |
| Фәйзуллин И.Г. | .”Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге” федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарындагы филиалы баш табибы (килештерү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ещев О.Л. | Россия ГХМ БИ нең ТР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм кисәтү эше Идарәсенең Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлекчәсе башлыгы (килештерү буенча) |
| Ханиева Р.Н. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы<br>балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссиянең җаваплы сәркатибе |
| Вәлиуллин З.Р. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы<br>“Муниципаль заказ хезмәте”” ҮКУ директоры |
| Баһаутдинова Г.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча бүлек башлыгы |
| Иминова Р.Г. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балалар иҗат үзәге”” өстәмә белем бирү үзидарәлек бюджет учреждениесе директоры |
| Минһаҗева Т.Г. | “ТАТМЕДИА” АҖ филиалы директоры – “Авыл офыклары” район газетасының баш мөхәррире (килештерү буенча) |
| Имамов Р.Х. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы<br>“”Дельфин” спорт-сәламәтләндерү комплексы” үзидарәлек бюджет учреждениесе директоры (килештерү буенча) |
| Рәшитова Р.Г. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” үзидарәлек казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
